билгеләнергә тиеш, мәсәлән кандагы шикәрнең артып китүе, сидек юлларындагы инфекцияләр. Диагноз расланса, врач бу үзгәрешләрне киметә яки гомумән бетерә ала торган дарулар язып бирә.

ДИАБЕТИК ПОЛИНЕЙРОПАТИЯ

Моннан тыш, озак вакытка сузылган гипергликемия периферия нервларын җәрәхәтли. Бу диабетик полинейропатия дип аталган үзгәрешләр неврапотолог тарафыннан гына билгеләнә ала. Аяклар авыртуы, көзән җыеру, бармаклар оюы, физик хәрәкәтләр ясаганда һәм йөргәндә тиз ару, артык күп тирләү, тән җәрәхәтләренең озак терелүе кебек симптомнар булганда невропатологка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Шуның турында да онытмагыз, бу билгеләр озакка сузылган гипергликемия белән дә бәйле була ала.

МОННАН ТЫШ АЯКЛАРНЫ КАРАУ БУЕНЧА БЕРНИЧӘ КИҢӘШ БИРЕП ҮТӘСЕ КИЛӘ.

- Аякларыгызны туңдырмагыз, җылы йон оеклар киеп аларны җылытыгыз, махсус җылыткычлар кулланмагыз, чөнки аякларыгызның сизгерлеге төшеп, тирене яндыру мөмкинлеге бар.
- Кояшта кызынганда янудан сакланыгыз.
- Пляжда аяк киемсез йөрергә тырышмагыз, чөнки аякларыгызны җәрәхәтләргә мөмкинсез.
- Аяк киеме уңайлы булырга һәм үкчә озынлыгы 5 смдан да артмаска тиеш.
- Көн дә аякларыгызны җылы су белән юыгыз. Аннары кортып сөртегез һәм махсус крем сөртегез.
- Аяк тырнакларын махсус пилкалар һәм кайчылар белән эшкәртергә кирәк, ялгыш тәнне җәрәхәтли күрмәгез.

→ Для обработки ногтей на ногах следует использовать пилки или ножницы с закругленными краями, подстригать ногти нужно не слишком коротко, чтобы не повредить кожу вокруг ногтей.

→ Носки должны быть хлопчатобумажными, и менять их следует ежедневно.

КАК ЧАСТО НУЖЕН ОСМОТР У НЕВРОПАТОЛОГА?

НЕ РЕЖЕ 1 РАЗА В ГОД.

При многолетней плохой компенсации диабета могут развиться нарушения в суставах рук (так называемая хайропатия). Это нарушение очень легко обнаружить самому. Появляется утолщение кожи пальцев рук, ощущение утренней скованности, пальцы становятся непослушными. Сложи ладонные поверхности кистей на всем протяжении, подняв локти так, чтобы предплечья образовали прямую линию (поза молящегося), и посмотри, плотно ли примыкают пальцы кистей рук друг к другу.

В норме пальцы смыкаются на всем протяжении. Наличие хайропатии не является опасным для здоровья, хотя и может затруднить выполнение работы, требующей повышенной гибкости пальцев (например, игра на музыкальном инструменте, работа с компьютером).

Однако появление хайропатии свидетельствует об очень плохой компенсации диабета. Нередко она развивается одновременно с другими осложнениями на глазах или в почках, чаще после 10 лет заболевания. Лечить хайропатию сложно, однако уменьшить ее позволяет физиотерапевтическое лечение (лазер, индуктотермия, ультразвук и т.д.) и хорошая компенсация диабета.

Таким образом, развитие осложнений при сахарном диабете в первую очередь зависит от того, насколько контролируется диабет, как хорошо удается поддерживать компенсацию.

→ Носкиларның киҗе-мамыклысын сайлагыз һәм аларны көн дә алыштырып торыгыз.

НЕВРОПАТОЛОГКА НИЧӘ ТАПКЫР КҮРЕНЕРГӘ КИРӘК?

ЕЛЫНА 1 ТАПКЫРДАН ДА КИМ БУЛМАСЫН.

Күпъеллык диабетны начар дәвалау сәбәпле кул буыннарында үзгәрешләр барлыкка килергә мөмкин (хайропатия). Бу үзгәрешне мөстәкыйль ачыклау шактый җиңел. Бармак тиресе калынайгандай була, иртәнге тәкәллефлек хисе барлыкка килә, бармаклар тыңлаусызга әйләнә. Учларыңны бергә куш, терсәкләреңне иң башлары туры бер сызык хасил итерлек итеп тоташтыр, һәм бармаклар тигез итеп тоташа алалармы, шуны тикшер.

Барсы да нормада булса бармаклар бертигез тоташа. Хайропатия сәламәтлек өчен зыянлы түгел, әмма шулай да кайбер бармаклар сыгылмалыгы кирәк булган эшләрне башкарганда комачаулый ала, мәсәлән музыка коралында уйнаганда яки компьютерда эшләгәндә.

Хайропатиянең барлыкка килүе диабет начар дәвалана дигән сүз. Еш кына ул күзләрдәге яки бөерләрдәге үзгәрешләр белән бергә авыруның дәвамлылыгы 10 елдан артып киткәч барлыкка килә ала. Хайропатияне дәвалау шактый авыр, әмма шулай да аны киметүне физиотерапевтик дәвалану ысулларын, ягъни лазер, индукт терапиясе, ультразвук һ.б. кулланып һәм диабетка игътибарны арттырып башкарырга мөмкин.

Шулай итеп, шикәр диабеты авыруының кискенләшүе беренче чиратта диабетны ни дәрәҗәдә контрольдә тоту һәм аны ничек дәвалау белән бәйле.

ФИЗИЧЕСКОЕ РАЗВИТИЕ

Одним из важных параметров компенсации углеводного обмена является физическое развитие. При постоянно некомпенсированном диабете возможно нарушение темпов роста. Это легко установить самостоятельно.

ПРИБАВКА В РОСТЕ ЗАВИСИТ ОТ ВОЗРАСТА РЕБЕНКА И СОСТАВЛЯЕТ В НОРМЕ:

- В 1 — 3 года — около 10 см в год;
- От 3 до 13 лет — 5 — 7 см в год;
- В период полового созревания — 8 —13 см в год.

Если ребенок за год не вырос или прибавил в росте не более 1-2 см, скорее всего, диабет плохо компенсирован. Самой частой причиной задержки роста при сахарном диабете является его декомпенсация.

Обследование у специалистов (окулиста, невропатолога, нефролога) проводится не только для того, чтобы установить наличие того или иного нарушения, но и чтобы помочь своевременно предотвратить их прогрессирование.

ФИЗИК ҮСЕШ

Углеводларны үзләштерүдә иң мөһим параметр булып физик үсеш санала. Диабетны начар дәвалаганда үсү темплары бозылырга мөмкин. Моны мөстәкыйль ачыклап була.

БАЛАНЫҢ ҮСҮЕ АНЫҢ ЯШЕ БЕЛӘН БӘЙЛЕ ҺӘМ НОРМАДА ТҮБӘНДӘГЕЧӘ:

- 1 — 3 яшьтә – елына якынча 10 см
- 3 тән 13кә кадәр – елына 5 — 7 см
- женси яктан өлгергән яшьтә – елына 8 —13 см

Әгәр дә бер ел эчендә баланың буе 1- 2 смка артмаса, димәк диабетны дөрес дәваламыйлар. Үсмәүнең иң еш очрый торган сәбәбе ул – диабетка кирәкле игътибарны биреп битермәү.

Күз табибында, невропатологта, нефрологта күренүләр теге яки бу үзгәрешләрне ачыклау өчен генә түгел, ә аларны үз вакытында күреп алу һәм арттырма өчен дә кирәк.

ФИЗКУЛЬТУРА. СПОРТ

МОЖНО ЛИ ТЕБЕ ЗАНИМАТЬСЯ ФИЗКУЛЬТУРОЙ?

Сахарный диабет не повод для отстранения от физической активности. Диабет — это хотя и вынужденный, но дополнительный стимул для того, чтобы физкультура и спорт вошли в вашу жизнь.

ВЕДЬ ИЗ ЗАНЯТИЙ СПОРТОМ МОЖНО ИЗВЛЕЧЬ НЕСКОЛЬКО ВЫГОД.

→ Улучшение самочувствия: повышается гибкость тела, увеличивается сила мышц и их объем, так же как и объем легких (сердце и легкие начинают работать эффективнее).

→ Психологический аспект: упражнения помогают бороться со стрессами, укрепляют здоровье. Человек становится более энергичным в работе, более активным, меньше устает.

→ Контроль веса: упражнения помогают либо сбросить, либо набрать вес (при его недостатке). При этом снижение веса происходит в основном за счет потери жира, в то время как при соблюдении только одной диеты — и за счет ухода из организма жидкости и мышечной массы.

→ Упражнения способствуют снижению уровня сахара в крови и повышению возможности организма утилизировать (перерабатывать) глюкозу.

Прежде чем начать занятия по какой-либо программе, надо убедиться, что ваш диабет хорошо контролируем. Необходимо учитывать физическую нагрузку, так как любая мышечная работа усиливает действие инсулина, снижает содержание сахара в крови. При этом также снижается и потребность в инсулине, что может привести к развитию гипогликемии. Однако этот эффект наблюдается только при уровне глюкозы в крови ниже 15,0 ммоль/л. При уровне глюкозы в крови выше этих значений физическая активность может привести к повышению сахара в крови и появлению кетоновых тел в моче.

ФИЗКУЛЬТУРА. СПОРТ

ФИЗКУЛЬТУРА БЕЛӘН ШӨГЫЛЬЛӘНЕРГӘ ЯРЫЙМЫ?

Шикәр авыруы физик яктан актив булмаска сәбәб түгел. Физкультура белән шөгыльләнү диабет белән авырган кеше өчен мөһим. Шуңа күрә, бу авыруыгыз дөрес яшәү рәвеше белән яши башларга бер стимул булсын.

СПОРТНЫҢ ФАЙДАСЫ ШАКТЫЙ:

→ Ул үз-үзеңне ничек хис итүеңә тәэсир итә.Тән сыгылмалылыгын арттыра мускулларны көчәйтә һәм аларның күләме арта, үпкәләрне киңәйтә (йөрәк эффективрак һәм яхшырак эшли башлый.

→ Аның психологик файдасы да бар: физик күнегүләр стресларга каршы көрәшергә булыша, сәламәтлекне ныгыта.

→ Кешенең көче, чыдамлылыгы арта, ул массасын контрольдә тотарга өйрәнә.

→ Күнегүләр авырлыкны җыярга да югалтырга да ярдәм итә. Авырлыкның кимүе, нигездә, май югалту исәбенә була. Ә диета ярдәмендә масса югалтканда организмнан сыеклык һәм мускул массасы китә. Күнегүләр кандагы шикәр дәрәҗәсен киметергә һәм организмның глюкозаны утильләштерергә (эшкәртергә) ярдәм итә.

Берәр программа буенча дәресләр ала башлаганчы, диабетыгыз яхшы контрольдә тотылуын тикшерергә кирәк. Инсулин кадаганда физик йөкләнешне исәпкә алырга кирәк, мускулларны эшләтүче физик көч түгү инсулин тәэсирен көчәйтә, кандагы шикәр дәрәҗәсен киметә. Шул ук вакытта инсулинга ихтыяҗ да кими. Моның аркасында гипогликемия барлыкка китерергә мөмкин. Ләкин бу эффект кандагы глюкоза дәрәҗәсе 15,0 ммоль/лдан түбәнрәк булганда гына була. Кандагы глюкоза дәрәҗәсе шул дәрәҗәләрдән югары булганда, физик активлык кандагы шикәр дәрәҗәсе артуына да китерергә мөмкин.

ДЛЯ ТОГО ЧТОБЫ ЗАНЯТИЯ СПОРТОМ ОКАЗЫВАЛИ БЛАГОТВОРНОЕ ДЕЙСТВИЕ, НЕОБХОДИМО СОБЛЮДАТЬ ОПРЕДЕЛЕННЫЕ ПРАВИЛА:

→ Определить вид, длительность и силу физической нагрузки;

→ Соблюдать режим питания и инсулинотерапии;

→ Необходимо рассчитать в зависимости от вида физической нагрузки, что надо предпринять: съесть дополнительные ХЕ или уменьшить дозу инсулина;

→ Преподаватель физкультуры и сам ребенок должны хорошо знать симптомы гипогликемии и уметь оказать помощь при ее возникновении;

→ Иметь с собой легкоусвояемые углеводы;

→ Определять гликемию до, во время и после физических упражнений;

→ Не заниматься физической нагрузкой при плохом самочувствии или если уровень глюкозы в крови повысился до 15 ммоль/л и выше, особенно если в моче появились кетоновые тела.

КАКИМИ ВИДАМИ СПОРТА МОЖНО ЗАНИМАТЬСЯ?

При отсутствии осложнений больной сахарным диабетом может заниматься почти всеми видами спорта. Это волейбол, велосипедный спорт, бег, бадминтон, теннис, баскетбол.
Не рекомендуется заниматься теми видами спорта, которые опасны для жизни: подводное плавание, прыжки с парашютом, скалолазание, виндсерфинг (во время этих занятий очень опасно возникновение гипогликемий!). Также могут быть ограничены такие виды занятий, как плавание на большие расстояния и в течение длительного времени, так как возникновение гипогликемий в воде очень опасно. Тяжелая атлетика также связана с большими перегрузками (подъем больших тяжестей), что может привести при имеющихся осложнениях на глазах к

СПОРТ БЕЛӘН ШӨГЫЛЬЛӘНҮ УҢАЙ НӘТИҖӘЛӘР БИРСЕН ӨЧЕН КАЙБЕР КАГЫЙДӘЛӘРНЕ БЕЛЕРГӘ КИРӘК:

→ Физик авырлык төрен, озынлыгын һәм көчен дөрес сайлау мөһим

→ Ашау һәм инсулин терапиясе режимын тоту;

→ Физик авырлыкның төренә карап, өстәмә ипи микъдарен яки инсулин күләмен киметергә кирәк.

→ Физкультура укытучысы һәм бала үзе дә гипогликемия билгеләрен яхшы белергә һәм кирәк чакта ярдәм күрсәтә алырга тиеш;

→ Үзең белән җиңел эшкәртелә торган углеводлар йөртергә кирәк:

→ Физик күнегүләрне ясар алдыннан, ясаганда һәм ясаганнан соң гликемияне тикшереп торыргаи кирәк;

→ Әгәр үзеңне начар хис итсәң яки кандагы глюкоза күләме 15 ммоль/л кадәр һәм югарырак күтәрелгән булса, шулай ук сидектә кетон матдәләр барлыкка килсә физик күнегүләр ясамаска кирәк;

СПОРТНЫҢ НИНДИ ТӨРЛӘРЕ БЕЛӘН ШӨГЫЛЬЛӘНЕРГӘ ЯРЫЙ?

Шикәр диабеты белән авыручыларда кискенләшү булмаган очракта спорт төрләренең бөтенесе белән дә шөгыльләнергә мөмкин. Мәсәлән, волейбол, велосипедта йөрү, йөгерү, бадминтон, теннис, баскетбол. Яшәү өчен куркыныч булган спорт төрләре белән шөгыльләнү кирәк дип саналмый, ягъни дайвинг, парашют белән сикерү, кыяга менү, виндсерфинг, алар белән шөгыльләнгәндә гипогликемия барлыкка килә ала. Шулай ук ерак арага һәм озак вакытка йөзү кебек спорт төрләре дә тыелырга мөмкин, чөнки суда гипогликемия бигрәк тә куркыныч. Авыр атлетика шулай ук артык йөкләнүләр белән бәйле, мәсәлән авыр әйберләр күтәрү кан юлларына тәэсир итә, күзләргә кан салу куркынычы барлыка килә. Шуңа күрә, мондый физик күнекмәләр белән шөгыльләнү шикәр диабеты белән авыручылар өчен зарарлы.

появлению новых кровоизлияний, и поэтому такие занятия также нежелательны при сахарном диабете.

Необходимо помнить, что иногда физические нагрузки и сильные эмоциональные стрессы могут вызвать резкие колебания сахара от гипогликемии до значительного повышения уровня глюкозы в крови и появления кетоновых тел в моче. Чтобы убедиться в стабильности уровня глюкозы в крови, необходимо его определить до начала упражнений, во время и после их завершения. Желательно фиксировать крайние значения этих измерений, длительность упражнений, время, прошедшее от последнего приема пищи до начала занятий, качественный состав пищи. Потом обсудить полученные результаты с врачом и совместно составить программу по оптимизации периодичности и введению инсулина.

ПОВЕДЕНИЕ ВО ВРЕМЯ ЗАНЯТИЙ СПОРТОМ

Наши рекомендации помогут спланировать и начать занятия спортом. Физическая нагрузка может быть короткой (1—2 ч) и длительной — несколько часов и даже дней. В зависимости от вида физической нагрузки необходимо выполнять различные рекомендации. Предотвращение гипогликемии при короткой физической нагрузке осуществляется добавлением в рацион питания лишних углеводов (ХЕ).

Следует помнить следующее правило. За 30 мин до физической активности необходимо съесть дополнительные ХЕ.

Рекомендации по приему дополнительных ХЕ при кратковременной физической активности приведены в таблице ниже. (Таблица 11)

Уровень глюкозы в крови после еды определяется для инсулина короткого действия через 3 ч после еды, для инсулина ультракороткого действия — через 2 ч. Величина сахара крови после еды отражает адекватность дозы короткого инсулина, введенного перед едой. Если ребенку предстоит легкая физическая нагрузка при показателях уровня глюкозы в крови до еды ниже 8 ммоль/л или после еды ниже 11 ммоль/л, то ему необходимо съесть дополнительно 1 ХЕ. При предстоящей средней, тяжелой физической активности — съесть от 2 до 4

Шунысын истән чыгармаска кирәк: физик активлык һәм каты эмоциональ стресслар кандагы шикәр күләмен бик нык күтәрергә мөмкин. Гипогликемиядән һәм сидектә кетон матдәләре барлыкка килү мөмкинлеге бар. Кандагы глюкоза күләменең күнегүләр ясау алдыннан, ясаганда һәм ясаганнан соң тикшерергә кирәк. Бу күрсәткечләрне истә калдырып, күнегүләрнең озынлыгын, шөгыльләнә башлау алдыннан һәм соңгы ашау вакытын истә тотып, киләсе ашаганда ризыкны маттдәләр төзелеше ягыннан дөрес сайларга. Шуннан соң авыруны карый торган врач белән киңәшләшеп, инсулин кадауга караган программа төзергә була.

СПОРТ БЕЛӘН ШӨГЫЛЬЛӘНҮ ТӘРТИБЕ

Безнең киңәшләр спорт белән шөгыльләнә башларга һәм киләчәктә планлаштырырга ярдәм итәчәк. Физик күнегүләр белән шөгыльләнү кыска (1-2 сәгать) яки озын (берничә сәгатьтән берничә көнгә кадәр) вакытлы була ала. Физик күнекмәләрнең төренә карап кайбер киңәшләргә игътибар итәргә кирәк.

Кыска вакытлы физик йөкләмәләр белән шөгыльләнгәндә гипогликемияне булдыртмас өчен рационга өстәмә углеводлар кушарга кирәк.

Түбәндәге кагыйдәне онытмаска. Физик күнегүләр белән шөгыльләнә башлаганчы 30 минут кала өстәмә углеводлар кабул итәргә кирәк. Шулай ук түбәндәге таблицада киңәшләр бирелгән. (Таблица 11)

Кандагы шикәр күләмен ашаганнан соң кыска вакытлы инсулин кулланганда 3 сәгатьтән, ә ультра кыска вакытлысыннан 2 сәгатьтән соң тикшерергә кирәк. Әгәр дә балага канында глюкоза күләме ашаганга кадәр 8 ммоль/л яки ашаганнан соң 11 ммоль/л булып, өстәмә физик көч түгәсе булса, димәк аңа өстәмә 1 ипи микъдарен сарыф итәргә кирәк була. Уртача, авыр физик йөкләмәләр көтелгән очракта, 2 — 4 — сарыф итәргә, әгәр дә гликемия булып ашаганчы 8 ммоль/л яки ашаганнан соң 11 ммоль/л кимрәк булса әлбәттә. Ашаганчы кандагы глюкоза 8—11 ммоль/л (ашаганнан соң 11—13) – 1-2 ипи микъдаре. Әмма җиңел физик күнегүләр башкарганчы кандагы глюкоза күләме (ашаганчы) 8 ммоль/л югарырак (һәм ашаганнан соң 11 ммоль/л югарырак)

ХЕ при гликемии до еды ниже 8 ммоль/л (или после еды ниже 11 ммоль/л). При глюкозе в крови до еды от 8 до 11 ммоль/л (после еды 11-13) — 1—2 ХЕ. Но, если перед легкой физической нагрузкой уровень глюкозы в крови до еды выше 8 ммоль/л (после еды выше 11 ммоль/л), углеводы не принимаются. Если перед средней или тяжелой физической активностью уровень глюкозы в крови до еды выше 11 ммоль/л (после еды выше 13 ммоль/л), рекомендованное количество дополнительных ХЕ составляет 0—1.
.
Кроме того, для предотвращения гипогликемий при кратковременной физической нагрузке можно снижать дозу инсулина (короткого или ультракороткого действия), но при этом необходимо учитывать время ее проведения.(Таблица 11—12)

ТАБЛИЦА 11

Время проведения	Рекомендации
Перед завтраком	Дополнительные ХЕ (после определения гликемии); Осторожно дозировать инъекцию инсулина перед завтраком
От 2 до 3 часов	Снижение дозы инсулина на 50% перед завтраком; Осторожно дозировать инъекцию инсулина перед обедом
Перед обедом	Дополнительные ХЕ (после определения гликемии); Осторожно дозировать инъекцию инсулина перед обедом;
От 2 до 3 часов после обеда	Снижением дозы инсулина на 50% перед обедом; Осторожно дозировать инъекцию инсулина перед обедом
Перед ужином	Дополнительные ХЕ (после определения гликемии); Осторожно дозировать инъекцию инсулина перед ужином
От 2 до 3 часов после ужина	Снижение дозы инсулина на 50% перед ужином; Снижение дозы инсулина на 10--25% перед поздним ужином; Перед сном прове-рить сахар крови

булганда өстәмә углеводлар кабул итәргә кирәкми. Әгәр дә уртача яки авыр физик йөкләмәләр эшләр алдыннан кандагы глюкоза күләме ашаганчы 11 ммоль/л югарырак, ашаганнан соң 13 ммоль/л югарырак булган очракта өстәмә углеводлар күләме – 0 —1 ипи микъдаре.

Моннан тыш, кыска вакытлы физик йөкләмә вакытында гипогликемия булмасын өчен инсулин (кыска яки ультра кыска вакытлы) күләмен киметергә мөмкин, әмма бу очракта аны кадау вакытын төгәл исәпләргә кирәк. (Таблица 11—12)

ТАБЛИЦА 11

Үткәрү вакыты	Тәкъдимнәр
Иртәнгә аш алдыннан	Кушма ИМ (гликимиядән соң); Иртәнгә аш алдыннан инъекцияне сак үлчәргә.
2 — 3 сәгать үткәч	Дозаны иртәнгә аш алдыннан 50%ка киметергә; Төшке аш алдыннан инъекцияне сак үлчәргә.
Төшке аш алдыннан	Кушма ИМ (гликимиядән соң); Төшке аш алдыннан инъекцияне сак үлчәргә.
Төшке аштан соң 2 — 3 сәгать үткәч	Дозаны төшке аш алдыннан 50%ка киметергә; Төшке аш алдыннан инъекцияне сак үлчәргә
Кичке аш ал-дыннан	Кушма ИМ (гликимиядән соң); Кичке аш алдыннан инъекцияне сак үлчәргә.
Кичке аштан соң 2 — 3 сәгать үткәч	Дозаны кичке аш алдыннан 50%ка киметергә; Соңгы кичке аш алдыннан 10--25%ка киметер-гә; Йокы алдыннан кан шикәре тикшерергә



ТАБЛИЦА 12

Время возникновения гипогликемии	Уменьшить дозу
Перед завтраком и/или ночью	Продленного инсулина перед ужином или перед сном
Перед обедом	Короткого инсулина перед завтраком или утреннего продленного инсулина при использовании ультракороткого инсулина, а также при значимой гипергликемии после завтрака
Перед ужином	Короткого инсулина перед обедом
Перед сном	Короткого инсулина перед ужином

При длительной физической нагрузке (продолжительностью более 1—2 ч: длительная езда на велосипеде, ремонт, поход, переезд, дискотека в течение нескольких часов) также необходимо корректировать дозу инсулина и (или) употреблять дополнительные ХЕ. Особенно надо быть внимательным при плавании. В воде происходит очень быстрый расход энергии.

ГИПОГЛИКЕМИЯ, ВОЗНИКШАЯ ВО ВРЕМЯ ПЛАВАНИЯ, ЧРЕЗВЫЧАЙНО ОПАСНА! (Таблица 13)

Во-первых, до начала занятий следует снизить дозу инсулина, активно действующего в период нагрузки, на 30 — 50%.

При гликемии ниже 5 ммоль/л не рекомендуется начинать длительную нагрузку. При таком уровне глюкозы в крови следует дополнительно съесть 2-4 ХЕ в зависимости от тяжести нагрузки. Если уровень глюкозы в крови от 5 до 9 ммоль/л, следует дополнительно съесть 1-2 ХЕ, при гликемии от 10 до 15 ммоль/л дополнительных ХЕ не требуется.

Следует помнить, что во время длительной нагрузки каждый час необходимо съедать 1-2 ХЕ.

ТАБЛИЦА 12

Гипогликемия вакыты	Дозаны киметергә
Иртәнгә аш алдыннан яки төнлә	Озайтылган инсулин кичке аш яки йокы алдыннан
Төшке аш алдыннан	Кыска инсулинның иртәнгә аш алдыннан яки иртәнгә инсулинның ультракыска инсулин куллансак һәм иртәнгә аш алдыннан гипергликемия булачак
Кичке аш алдыннан	Кыска инсулинның төшке аш алдыннан
Йокы алдыннан	Кыска инсулинның кичке аш алдыннан

Озак вакытлы физик йөкләмәләр вакытында (1 — 2 сәгатьтән артык булганнар: озак вакыт велосипедта йөрү, ремонт, поход, күченү, дискотека һ.б) шулай ук инсулин күләмен үзгәртергә һәм (яки) өстәмә ипи микъдарен ашарга мөмкин. Йөзү вакытында аеруча да игътибарлы булырга кирәк. Суда энергия бик тиз бетә.

СУДА ЙӨЗГӘНДӘ БАРЛЫККА КИЛӘ АЛА ТОРГАН ГИПОГЛИКЕМИЯ БИК КУРКЫНЫЧ. (Таблица 13)

Беренчедән, шөгыльләнә башлар алдыннан актив булган инсулин күләмен 30 – 50% киметергә кирәк.

5 ммоль/л булган гликемия вакытында озак вакытлы физик йөкләмәләр белән шөгыльләнмәскә кирәк. Канда мондый глюкоза күләме булганда йөкләмәнең авырлыгына карап, өстәмә 2-4 ипи микъдаре кабул итәргә кирәк. Әгәр дә кандагы глюкоза күләме 5 -9 ммоль/л кадәр булса, өстәмә 1-2 ипи микъдаре кабул итәргә, гликемия вакытында 10-15 ммоль/л глюкоза булса, өстәмә ипи микъдаре кабул итәргә кирәкми.

Шунысын да онытмаска кирәк, озак вакыт физик күнегүләр ясаган очракта һәр сәгать 1-2 ипи микъдаре кабул итеп торырга кирәк.

После окончания физической активности нужно проверить уровень глюкозы в крови. При сахаре крови менее 10 ммоль/л снизить после-дующую дозу инсулина на 30-50°/о. Кроме того, для предотвращения гипогликемий после тяжелых длительных нагрузок, которые могут развиваться в течение 12 — 24 ч, следует дополнительно съесть богатую углеводами пищу (макароны, картофель, рис).

Эффективность упражнений зависит от достаточности в организме инсулина, который заставляет мышечные клетки усваивать глюкозу для выработки энергии. Когда диабет компенсирован или имеется лишь небольшое повышение уровня глюкозы в крови при отсутствии кетоновых тел в моче, упражнения приводят к снижению содержания сахара в крови и потребности в вводимом инсулине. При этом снижение уровня сахара в крови может начаться в завершающей стадии упражнений или сразу после его завершения и длиться до 24 ч. Если диабет компенсирован недостаточно или не компенсирован вовсе, физическая активность может повысить уровень сахара крови, так как работающие мышцы, которым требуется энергия, посылают сигнал печени, которая выбрасывает большее количество глюкозы в кровь, тем самым усугубляя состояние во время упражнений и еще более декомпенсируя диабет.

ПОЭТОМУ, ЕСЛИ У ВАС ПОСЛЕ ФИЗИЧЕСКОЙ НАГРУЗКИ ОТМЕЧАЕТСЯ ПОВЫШЕНИЕ ГЛЮКОЗЫ В КРОВИ, НЕОБХОДИМО УЧЕСТЬ НЕСКОЛЬКО ПРИЧИН:

- отсутствие компенсации углеводного обмена;
- чрезмерное снижение дозы инсулина перед нагрузкой;
- чрезмерное употребление дополнительных ХЕ перед нагрузкой.

Физик активлык белән шөгыльләнеп бетергәч, кандагы глюкоза күләмен тикшерергә кирәк. Әгәр кандагы шикәр күләме 10 ммоль/л кимрәк булса, кабул итәсе инсулин күләмен 30-50% киметергә кирәк. Моннан тыш, авыр физик йөкләмәләрдән соң 12 — 24 сәгать дәвамында барлыкка килә ала торган гипогликемияләрне булдыртмас өчен углеводларга бай ризыклар ашарга кирәк, мәсәлән токмач, бәрәңге, дөге. Күнегүләрнең эффективлыгы организмда җитәрлек инсулин булуы белән билгеләнә, чөнки ул мускуллар күзәнәкләрен глюкозаны эшкәртергә мәҗбүр итеп, энергия чыгара. Диабет борчымаганда яки кандагы шикәр азга гына күтәрелгән булса һәм сидектә кетон матдәләре булмаса, физик күнегүләр кандагы шикәр күләмен һәм инсулинга мохтаҗлыкны киметәләр. Кандагы шикәр күләме киму физик йөкләмәләр бетер алдыннан яки беткәч үк башлана һәм 24 сәгатькә кадәр сузыла ала. Әгәр диабет дөрес компенсацияләнмәсә, физик активлык зарар гына китерәчәк: кандагы шикәр күләме арта, чөнки эшли торган мускулларга энергия кирәк була һәм алар бавырга “мөрәҗәгать” итәләр, ә бавыр канга бик күп глюкоза чыгарып, диабет белән авыручының хәлен начарайтырга мөмкин.

ШУҢА КҮРӘ ФИЗИК КҮНЕГҮЛӘР БЕЛӘН ШӨГЫЛЬ-ЛӘНГӘННӘН СОҢ КАНЫГЫЗДА ГЛЮКОЗА АРТСА КАЙБЕР СӘБӘПЛӘРГӘ ИГЪТИБАР ИТӘРГӘ КИРӘК:

- углевод алышы компенсациясе булмау
- йөкләмә алдында инсулин күләмен артык нык кимету
- йөкләмә алдыннан өстәмә ипи микъдарен артык кабул иту.

ТАБЛИЦА 13

Сахар крови	Рекомендации	
	Инсулин	Питание
Ниже 5	Уменьшать суточную дозу всех инсулинов на 30--50%	Съесть 2—4 ХЕ перед нагрузкой и при необходимости по 1--2 ХЕ каждый час нагрузки
5 — 9	То же самое	Съесть 1--2 ХЕ перед нагрузкой и при необходимости по 1--2 ХЕ каждый час нагрузки
10 — 15	То же самое	При необходимости есть не более 1 ХЕ каждый час нагрузки
Выше 15	Физические нагрузки запрещены	

ТАБЛИЦА 13

Кан шикәре	Тәкъдимнәр	
	Инсулин	Туклану
5 түбән	Көндәлек дозасы 30 — 50%га киметергә	Йөкләнеш алдыннан 2—4 ИМ ашарга һәм йөкләнешне һәр сәгате 1—2 ИМ
5 — 9	Шул ук	Йөкләнеш алдыннан 1 — 2 ИМ ашарга һәм йөкләнешне һәр сәгате 1 — 2 ИМ
10 — 15	Шул ук	Йөкләнешне һәр сәгате 1 ИМ артык түгел ашарга
15 артык	Физик эш тыелган	

ПОВЕДЕНИЕ ВО ВРЕМЯ ПУТЕШЕСТВИЙ

Принципиальных ограничений при выборе места проведения и вида летнего отдыха для детей с сахарным диабетом не существует. В целом пациенты с диабетом могут путешествовать и отдыхать точно так же, как отдыхают летом все дети. Не нужно отказываться от отдыха из-за диабета. Летние каникулы можно и нужно проводить так, как вы хотите. Это может быть отдых за городом, на море, туризм, оздоровительный детский лагерь, отдых за границей. Самое главное —следует очень хорошо ориентироваться во всех проблемах сахарного диабета, обязательно держать уровень глюкозы в крови под контролем и заранее позаботиться об определенных вещах!

Куда бы ребенок ни уезжал во время каникул, ему с собой необходимо в первую очередь взять инсулин, глюкометр, ланцеты, тест-полоски для глюкометра, шприц-ручки и иглы для них или расходные материалы для помпы. Количество инсулина, необходимого на время отпуска, можно рассчитать следующим образом: средний расход на отпуск + 2 дополнительных пенфилла (минимум), но лучше взять двойной запас. Для того чтобы чувствовать себя во время отдыха уверенно в любой ситуации, тест-полосок нужно взять с собой как минимум в 2 раза больше обычного количества. Не забудьте запастись достаточным количеством игл для шприц-ручек. При подготовке к отпуску не забудьте взять с собой инсулиновые шприцы, даже если в повседневной жизни вы ими не пользуетесь. Это необходимо для тех случаев, когда по какой-либо причине ломается используемая постоянно шприц-ручка.

ЕСЛИ ПЛАНИРУЕТСЯ ПУТЕШЕСТВИЕ ЗА ГРАНИЦУ, СЛЕДУЕТ ОБЯЗАТЕЛЬНО ВЫЯСНИТЬ УСЛОВИЯ ПРОЖИВАНИЯ В ЭТОЙ СТРАНЕ ДО ОТПРАВЛЕНИЯ.

Во время путешествий на самолете и при пересечении границы следует заранее взять справку от лечащего врача, подтверждающую наличие у ребенка сахарного диабета и обосновывающую необходимость перевоза в ручной клади инсулина, шприц-ручек, глюкометра, тест-полосок, игл и т.д.

СӘЯХӘТТӘ

Шикәр авыруы булган балалар өчен җәйге ял урынын һәм ял төрен сайлаганда принципиаль чикләүләр юк. Гомумән алганда, шикәр авыруы булган пациентлар башка балалар кебек үк сәяхәт итә һәм ял итә ала. Диабет аркасында ял итүдән баш тартырга кирәкми. җәйге каникулларны ничек телисез шулай үткәрергә кирәк. Бу шәһәр читенә чыгып ял итү, диңгезгә бару, туризм, балалар сәламәтләндерү лагерына бару, чит илдә ял итү булырга мөмкин. Иң мөһиме — шикәр авыруының барлык мәсьәләләрне да яхшы итеп өйрәнергә, кандагы глюкоза дәрәҗәсен контрольдә тотарга һәм алдан билгеле бер әйберләр турында кайгыртырга кирәк!

Каникуллар вакытында бала кая гына китмәсен, аңа беренче чиратта инсулин, глюкометр, ланцетлар, глюкометр өчен тест-тасмалар, шприц-ручкалар һәм энәләр яки помпа өчен материаллар алырга кирәк. Отпуск вакытына кирәкле инсулин күләмен түбәндәгечә исәпләргә мөмкин: ялның һәрбер көненә исәпләнгән уртача дозалар + 2 өстәмә пенфилл (минимум), ләкин икеләтә запас алу яхшырак. Ял вакытында үзегезне ышанычлы хис итү өчен тест-тасмаларны, ким дигәндә, гадәттәгедән ике тапкыр күбрәк алырга кирәк. Шприц-ручкалар өчен кирәкле санда энәләр алырга онытмагыз. Ялга әзерләнгәндә үзегез белән инсулин шприцларын алырга онытмагыз, хәтта көндәлек тормышта алардан файдаланмасагыз да. Бу нинди дә булса сәбәп аркасында даими кулланыла торган шприц-ручка ватылган очраклар өчен кирәк.

ЧИТ ИЛГӘ СӘЯХӘТ ПЛАНЛАШТЫРЫЛГАН ОЧРАКТА, КИТҮ АЛДЫННАН БУ ИЛДӘГЕ ЯШӘҮ ШАРТЛАРЫН АЧЫКЛАРГА КИРӘК.

Самолетта сәяхәт итү һәм берәр илнең чиген узу вакытында дәвалаучы табибтан балада шикәр авыруы булуын һәм кул йөгендә инсулин, шприц-ручка, глюкометр, тест-тасмалары, энәләр һәм башка әйберләр йөртүнең кирәклеген раслый торган белешмә алырга кирәк.

ПОВЕДЕНИЕ ВО ВРЕМЯ ПУТЕШЕСТВИЙ

Если вы едете за границу, то не забудьте оформить медицинскую страховку, только предупредите, что у ребенка сахарный диабет. Во время отпуска обязательно нужно иметь с собой глюкагон [набор для инъекций глюкагона (ГлюкаГен 1 мг ГипоКит)] для того, чтобы оказать первую помощь в случае тяжелой гипогликемии.

Поскольку инсулин всегда должен быть при себе и на отдыхе на море, и во время катания на лыжах зимой, мы хотим напомнить несколько важных правил хранения инсулина.
Запас инсулина должен обязательно храниться в холодильнике. Используемые в настоящее время шприц-ручки с инсулином в любой поездке нужно держать при себе или в ручной клади — в кармане брюк, куртки, в сумке через плечо. В багажном отделении самолета инсулин может замерзнуть, и тогда использовать его будет нельзя. При поездке в автомобиле следует тоже держать инсулин при себе. Нельзя класть сумку с инсулином на полку заднего стекла автомобиля или на консоль под ветровым стеклом (инсулин может перегреться). Во время летнего отдыха инсулин всегда нужно защищать от воздействия прямых солнечных лучей и нагревания свыше 40 ˚С. При этих условиях инсулин сохраняет свою активность и может быть использован в течение 4 нед.

Защитить шприц-ручку от воздействия прямых солнечных лучей можно, завернув инсулин во влажный носовой платок, а на пляже нужно обязательно убирать в тень (под лежак). В жарком климате при-годятся специальные сумочки с охлаждающим элементом для хранения инсулина.

Во время зимнего отдыха инсулин следует защищать, прежде всего, от замерзания (ниже 2 ˚С). Поэтому носить его лучше непосредственно на теле (например, во внутреннем кармане куртки или в поясной сумке под курткой во время лыжной прогулки). Там же следует носить и тест-полоски. Проводить измерение уровня глюкозы в крови лучше при комнатной температуре.

Помимо всего вышеперечисленного, во время отдыха и путешествий могут понадобиться другие средства и препараты, которые вполне можно купить в любой аптеке.

СӘЯХӘТТӘ

Чит илгә барган очракта, медицина иминиятен рәсмиләштерергә онытмагыз һәм бу очракта балада шикәр авыруы булуын кисәтегез. Ял вакытында үзегез белән мәҗбүри рәвештә глюкагон [глюкагон иньекцияләре өчен җыелма (Глюкагон 1 мг ГипоКит)] йөртергә кирәк. Бу авыр гипогликемия очрагында беренче ярдәм күрсәтү өчен кирәк. Диңгездә ял иткәндә дә, кышын чаңгыда шуган вакыта да инсулин һәрчак үзегез белән булырга тиеш булганлыктан, без инсулин саклауның берничә мөһим кагыйдәсен искә төшереп китәбез. Инсулин запасы һичшиксез суыткычта сакланырга тиеш.

Әлеге вакытта кулланыла торган шприц-ручкалар белән инсулинны һәр сәфәрдә дә үзегез белән кул йөгендә - ыштан, куртка, сумка кесәсендә йөртергә кирәк. Самолетның багаж бүлегендә инсулин бозланып катырга мөмкин һәм аны алга таба кулланырга ярамый. Автомобильдә булганда да инсулинны янәшә тотарга кирәк. Инсулин салынган сумканы автомобильнең арткы пыяласы киштәсенә яки алгы пыяласы астындагы консольгә салырга ярамый (инсулин җылынырга мөмкин). җәйге яллар вакытында инсулинны кояш нурларыннан һәм 40 С-ка кадәр булган җылыну-дан сакларга кирәк.

Бу шартларда инсулин үзенең активлыгын саклап кала һәм 4 атна дәвамында кулланылырга мөмкин. Инсулинны дымлы кулъяулыкка төреп, шприц-ручканы турыдан-туры кояш нурлары тәэсиреннән сакларга мөмкин, ә пляжда аны күләгәгә кую зарури. Эссе климатта инсулин саклау өчен суыклыкны саклый торган махсус сумкалар кирәк булачак.

Кышкы ял вакытында инсулинны, барыннан да элек, туңудан (2 С тан кимрәк) сакларга кирәк. Шуңа күрә аны тән янында йөртү яхшырак (әйтик, эчке кесәдә куртка яки чаңгы йөргәндә куртка янындагы бил сумкасында). Шунда ук тест-тасмаларын да йөртергә була. Кандагы глюкоза дәрәҗәсен тикшерүне бүлмә температурасында уздыру яхшырак. Алда саналган әйберләрдән кала, ял һәм сәяхәтләр вакытында теләсә кайсы даруханәдә сатып алырга мөмкин булган башка чаралар һәм препаратлар кирәк була ала.

ПОВЕДЕНИЕ ВО ВРЕМЯ ПУТЕШЕСТВИЙ

Это дезинфицирующие растворы (перекись водорода), стерильные марлевые салфетки, бактерицидный лейкопластырь и т.д., средства от солнечных ожогов (например, Пантенол), несколько пакетиков Энтеродеза (на случай появления кетоновых тел), средства и препараты, которыми обычно в домашних условиях вы пользуетесь при лечении простудных заболеваний (капли в нос, ушные и глазные капли и т.д.) и желудочно-кишечных расстройств.

Если вам трудно определиться в подборе ассортимента при составлении подобной аптечки скорой помощи, посоветуйтесь со своим лечащим врачом.

Универсального решения вопроса, как изменять инсулинотерапию при сдвиге времени, не существует. У каждого своя индивидуальная приспособляемость. Потребность в инсулине при длительных перелетах зависит от направления перелета. При перелете в направлении восток-запад день становится длиннее, и потребность в инсулине увеличивается. При перелете запад-восток день становится, наоборот, короче, и потребность в инсулине снижается.

С целью приспособления режима инсулинотерапии к изменению режима времени в том месте, где вы проводите отпуск (смена часовых поясов), рекомендуется более частый контроль гликемии - каждые 3 ч или даже чаще! Особенно необходим контроль уровня глюкозы в крови в ночные часы. В зависимости от полученных результатов следует решить вопрос о необходимости выполнения дополнительных инъекций короткого инсулина. Пролонгированный инсулин в этот период вводится как обычно. В случае удлинения или укорочения дня основная доза инсулина дополняется более частой корректировкой коротким инсулином (по показаниям содержания уровня глюкозы в крови каждые 3 ч). Во время отдыха, проводимого вне дома, не исключено, что еда и время приема пищи будут отличаться от тех, к которым ребенок привык дома. Для того чтобы избежать повышения или понижения уровня глюкозы в крови, необходимо дополнительно контролировать уровень глюкозы в крови всякий раз, когда возникают сомнения.

СӘЯХӘТТӘ

Бу дезинфекцияләү эремәләре (водород перекисе), стериль марля салфеткалары, бактерицид лейкопластырь һәм башкалар, кояшта тән пешүгә каршы чаралар (мәсәлән: Пантенол), берничә пакет Энтеродез (кетон җисемнәре барлыкка килү очрагында), гадәттә өй шартларында салкын тию (борын тамчылары, колак һәм күз тамчылары һәм башкалар) һәм ашказаны авыруларын дәвалаганда файдалана торган чаралар һәм препаратлар.

Сезгә мондый ашыгыч ярдәм дарулары пакетын җыештырган-да ассортиментны сайлау кыен булса, дәвалаучы табиб белән киңәшләшегез.

Вакыт күчергәндә инсулинотерапияне ничек итеп үзгәртү мәсьәләсенең универсаль хәл ителеше юк. Һәркем үзенчә җайлаша. Озак очу вакытында инсулинга ихтыяҗ очып киту юнәлешенә бәйле. Көнчыгыш-Көнбатыш юнәлешенә күчкәндә көн озыная бара һәм инсулинга ихтыяҗ арта. Көнбатыштан Көнчыгышка таба очканда, киресенчә, көн кыскара, һәм инсулинга ихтыяҗ кими. Инсулинотерапия режимын сез ял иткән урындагы (сәгать поясларын алмаштырган урында) вакыт режимына җайлаштыру максаты белән гликемиянең шәхси контролен ешрак уздырырга киңәш ителә — һәр 3 сәгать саен яки тагы да ешрак! Бигрәк тә төнге сәгатьләрдә кандагы глюкоза дәрәҗәсен контрольдә тоту зарур. Алынган нәтиҗәләргә бәйле рәвештә, кыска инсулинның өстәмә инъекцияләрен кертү кирәклеге турындагы мәсьәләне хәл итәргә кирәк. Әлеге вакытта озынайтылган инсулин дозасы гадәттәгечә кертелә. Көн озынайган яки кыскарган очракта инсулинның төп дозасы кыска инсулин дозалары белән (кандагы глюкозлар дәрәҗәсен һәр 3 сәгать саен карап тоту күрсәткечләре буенча) тулыландырыла.

ПОВЕДЕНИЕ ВО ВРЕМЯ ПУТЕШЕСТВИЙ

Чтобы избежать гипогликемии в случае непредсказуемой задержки очередного приема пищи, с собой обязательно следует брать углеводсодержащие продукты (например, фрукты, хлеб). А для купирования уже возникшей гипогликемии с собой всегда должен быть сахар, сок или сладкий напиток.

Следует обязательно помнить о том, что при повышенной физической активности (плавание, бег, катание на роликах, футбол спортивные игры и т.д.) риск возникновения гипогликемии возрастает. Поэтому очень важно следить за уровнем глюкозы в крови и вовремя принимать меры для предотвращения гипогликемии — съедать больше углеводсодержащих продуктов или снижать дозу инсулина перед началом нагрузки.

ДИАБЕТ И АЛКОГОЛЬ У ПОДРОСТКОВ

Во многих странах употребление алкоголя до наступления совершеннолетия (а во многих странах это 21 год, а не 18) строго запрещено законом. Тем более недопустимо употребление алкоголя подросткам с сахарным диабетом.

Чем же опасен алкоголь при диабете? В первую очередь способностью вызвать гипогликемию. Происходит это потому, что алкоголь блокирует глюконеогенез — процесс образования глюкозы в печени. Одновременно снижается способность человека распознавать предвестники гипогликемии, что повышает риск развития тяжелой гипогликемии.

> **ПРИ ГИПОГЛИКЕМИИ, ВЫЗВАННОЙ УПОТРЕБЛЕНИЕМ АЛКОГОЛЯ, ИНЪЕКЦИЯ ГЛЮКАГОНА НЕ ЭФФЕКТИВНА, И МОЖЕТ ПОТРЕБОВАТЬСЯ ВНУТРИВЕННОЕ ВВЕДЕНИЕ ГЛЮКОЗЫ!**

И, наконец, симптомы гипогликемии могут быть ошибочно расценены другими людьми как симптомы опьянения. И помощь не будет оказана вовремя. Таким образом, употребление алкоголя может привести к очень серьезным проблемам для здоровья и даже угрожать жизни в случае тяжелой гипогликемии. Будьте достаточно взрослым, чтобы с достоинством уметь отказаться от алкоголя.

СӘЯХӘТТӘ

Өйдән читтә үткәрелгән ял вакытында ашау һәм ризык кабул итү вакыты өйдә күнеккәннән аерылырга мөмкин. Кандагы глюкоза дәрәҗәсен күтәрмәү яки киметмәү өчен, шик туган саен кандагы глюкоза дәрәҗәсен өстәмә контрольдә тотарга кирәк. Гипогликемияне булдырмас өчен, чираттагы аш кабул итү вакытында, үзегез белән углеводлы азык-төлек алырга кирәк (мәсәлән:җиләк-җимеш, икмәк). Ә инде килеп чыккан гипогликемияне атлату өчен янычгызда һәрчак шикәр, сок яки баллы эчемлек булырга тиеш. Физик активлык (йөзү, йөгерү, роликларда йөрү, футбол спорт уеннары һәм башкалар) күбрәк булганда гипогликемия барлыкка килү куркынычы арта. Шуңа күрә кандагы глюкозаның дәрәҗәсен тикшереп тору һәм гипогликемияне булдырмау өчен вакытында чаралар күрү - күбрәк углеводородлы продуктларны ашарга яки күнегүләр эшләү алдыннан инсулин дозасын киметергә кирәк.

ЯШҮСМЕРЛӘРДӘ ШИКӘР АВЫРУЫ ҺӘМ АЛКОГОЛЬ.

Күп кенә илләрдә балигъ булмаганнар арасында алкоголь эчү закон белән катгый рәвештә тыела (күп кенә илләрдә бу 21 яшь түгел, ә 18 яшь). Өстәвенә, шикәр авыруы булган яшүсмерләргә алкоголь эчү бөтенләй ярамый.

Шикәр авыруы булганда алкоголь нәрсәсе белән куркыныч? Беренче чиратта гипогликемия китереп чыгара алуы белән. Бу алкоголь глюконеогенезны — бавырдагы глюкозлар барлыкка килү процессын томалый. Бер үк вакытта кешенең гипогликемия симптомнарын тану сәләте кими, бу авыр гипогликемия үсеше куркынычын арттыра.

> **АЛКОГОЛЬ КУЛЛАНУДАН БАРЛЫККА КИЛГӘН ГИПОГЛИКЕМИЯ ВАКЫТЫНДА ГЛЮКАГОН ИНЪЕКЦИЯСЕ НӘТИҖӘЛЕ ТҮГЕЛ ҺӘМ ГЛЮКОЗАНЫ КАН ТАМЫРЫ АША КЕРТҮ КИРӘК БУЛЫРГА МӨМКИН!**

Ниһаять, гипогликемия симптомнары башка кешеләр тарафыннан исерү симптомнары буларак кабул ителергә мөмкин. Ярдәм үз вакытында күрсәтелми. Шулай итеп, алкоголь эчү сәламәтлек өчен җитди проблемаларга китерергә һәм хәтта авыр гипогликемия очрагында, тормышка куркыныч тудырырга мөмкин. Алкогольдән баш тартыгыз!

ПОВЕДЕНИЕ ВО ВРЕМЯ ПУТЕШЕСТВИЙ

ВАКЦИНАЦИЯ И ДИАБЕТ

При диабете не существует принципиальных ограничений для проведения вакцинации. Вакцинация проводится по тому же календарю, как у других детей, при условии компенсированного сахарного диабета в течение последних 3 мес, удовлетворительном общем состоянии, под контролем педиатра и эндокринолога.



СӘЯХӘТТӘ

ВАКЦИНАЦИЯ ҺӘМ ДИАБЕТ

Диабет булганда вакцинацияләр өчен чикләүләр юк. Соңгы 3 ай дәвамында диабетның компенсацияле булуы һәм баланың үзен яхшы хис итүе шарты белән вакцинация башка балалардагыча, шул ук календарь тәртибендә педиатр һәм эндокринолог күзәтүе астында үткәрелә.



ШКОЛЬНЫЕ БУДНИ

Понимание проблем, связанных с сахарным диабетом, со стороны педагогов, их поддержка, умение грамотно реагировать на возможные изменения самочувствия будут залогом спокойствия самого ребенка, их собственного и, конечно, родителей.

Как правило, люди боятся диабета, потому что мало знают о нем. Поэтому задача семьи и врача - познакомить не только учителей, школьную медсестру, но и лучших школьных товарищей (если есть возможность и желание, то и весь класс!) с некоторыми основами сахарного диабета.

О ЧЕМ ЖЕ СЛЕДУЕТ РАССКАЗАТЬ?

Чаще всего дети с сахарным диабетом сталкиваются с проблемами низкой концентрации глюкозы в крови, своевременного приема пищи, необходимости контроля уровня сахара крови и выполнения дополнительных инъекций инсулина в случае повышения сахара крови.

НАИБОЛЬШУЮ УГРОЗУ В ШКОЛЕ ПРЕДСТАВЛЯЕТ СОБОЙ ГИПОГЛИКЕМИЯ:

> опасны момент ее возникновения и последствия ее несвоевременного и неправильного купирования. Учителям следует знать о том, что такое гипогликемия, какими симптомами она сопровождается и, самое главное, как данное состояние лечить. Необходимо предупредить педагогов о том, что возникнуть гипогликемия может в любое время — на перемене, во время урока, написания контрольной работы. Поэтому и принимать нужные меры — выпить сок или съесть 2—4 кусочка сахара - нужно сразу, как только возникли первые симптомы.

НИ В КОЕМ СЛУЧАЕ НЕ НУЖНО ЖДАТЬ ПЕРЕМЕНЫ!

К тому времени, когда у ребенка появится возможность выйти из класса, уровень глюкозы в крови может снизиться до критического или, наоборот, уже поднимется самостоятельно, и дополнительный прием углеводов только ухудшит ситуацию.

УКУ ҺӘМ ДӘРЕСЛӘР ВАКЫТЫНА КИҢӘШЛӘР

Шикәр диабеты белән бәйле проблемаларны аңлау, кирәк чакта авыру балага ярдәм итү, мөмкин булган үзгәрешләренә дөрес реакция бирү балалар, ата-аналар һәм педагогларның үзләре өчен дә тынычлыкның нигезе. Кеше диабет турында әз белгәнгә күрә курка.

Шуңа күрә, гаилә һәм табибның бурычы-укытучыларны, мәктәптәге медсестраны, гына түгел, мәктәп иптәшләрен дә (мөмкинлек һәм теләк булса, бөтен сыйныфны) шикәр диабетының кайбер үзенчәлекләре белән таныштыру.

НӘРСӘ ТУРЫНДА СӨЙЛӘРГӘ КИРӘК СОҢ?

Ешрак шикәр диабеты булган балалар кандагы глюкозларның концентрациясе, түбән булган вакытта ашау, кан шикәре дәрәҗәсен контрольдә тоту һәм кандагы шикәр арткан очракта, инсулинның өстәмә инъекция ясалуын контрольдә тоту кирәклеге белән каршылаша.

МӘКТӘПТӘ УКЫГАНДА ГИПОГЛИКЕМИЯ АЕРУЧА КУРКЫНЫЧ БУЛЫРГА МӨМКИН:

> аның кисәк, бик урынсыз булуы һәм вакытлы яки дөрес ярдәм күрсәтелмәве куркыныч. Укытучыларга гипогликемиянең нәрсә икәнлеген, аның нинди симптомнар белән кичүен һәм, иң мөһиме, бу халәттә, нинди чара күрергә кирәклеген белергә кирәк. Педагогларны алдан ук гипогликемия булырга мөминлеге турында кисәтеп куярга кирәк. Шуңа күрә, беренче симптомнар барлыкка килгәнче үк чаралар күрергә — балага сок эчәргә яки 2 — 4 кисәк шикәр ашарга кирәк.

ТӘНӘФЕСНЕ КӨТМӘГЕЗ!

Балага сыйныфтан чыгарга яраган вакыт җиткәч, кандагы глюкоза дәрәҗәсе кискен кимергә яки, киресенчә, мөстәкыйль күтәрелергә мөмкин һәм мондый очракта углеводларны өстәмә кабул итү хәлне начарайтачак кына.

ШКОЛЬНЫЕ БУДНИ

Учителей следует проинформировать о том, как помочь в случае возникновения и более грозного состояния — тяжелой гипогликемии. Нужно рассказать о тех симптомах, которыми тяжелая гипогликемия может проявиться и как правильно ввести глюкагон. В школе должны быть обязательно телефоны родителей, по которым в случае нештатной ситуации с ними можно было бы сразу связаться.

ВЫБОР БУДУЩЕЙ ПРОФЕССИИ

Выбор профессии является очень важным вопросом. Нужно выбрать такую специальность, которая могла бы обеспечить соблюдение режима дня, питания и возможность делать инъекции инсулина в необходимое время.

ПРИ САХАРНОМ ДИАБЕТЕ ИМЕЮТСЯ СУЩЕСТВЕННЫЕ ОГРАНИЧЕНИЯ ПРИ ВЫБОРЕ ПРОФЕССИЙ, КОТОРЫЕ СВЯЗАНЫ:

- → с большими физическими нагрузками (грузчик, шахтер);
- → значительным нервно-психологическим напряжением (авиадиспетчеры, служба в армии, водитель наземного, подземного и водного транспорта, пилот);
- → ненормированным рабочим днем или работой в ночное время;
- → неблагоприятным микроклиматом (низкая или высокая температура);
- → контактом с токсическими веществами (работа на химическом производстве).

Можно рекомендовать учебу в фармацевтических и медицинских институтах и колледжах, педагогическом, сельскохозяйственном, экономическом, юридическом институтах, многих технических вузах, работу в библиотеках, архивах, школах, торговле и т.д.

УКУ ҺӘМ ДӘРЕСЛӘР ВАКЫТЫНА КИҢӘШЛӘР

Укытучыларга алдан ук гипогликемия булган очракта, балага ничек ярдәм итәргә кирәклеге турында хәбәр итү бик әһәмиятле.



Авыр гипогликемия барлыкка килгәндәге симптомнарны һәм глюкагонны дөрес итеп бирү ысулы турында сөйләргә кирәк. Очрактан тыш хәл булса, алар белән тиз арада элемтәгә керергә мөмкин булсын өчен, мәктәптә, һичшиксез, ата-аналарның телефон номерлары булырга тиеш.

ҺӨНӘР САЙЛАУ

Киләчәк һөнәрне сайлау бик мөһим мәсьәлә булып тора. Көн режимын үтәү, туклану һәм инсулин иньекциясен вакытында ясау мөмкинлеге бирә торган белгечлеккә күбрәк өстенлек бирергә кирәк.

ШИКӘР ДИАБЕТЫНА БӘЙЛЕ ҺӨНӘРЛӘР САЙЛАГАНДА ҖИТДИ ЧИКЛӘҮЛӘР БАР:

- → зур физик көч түгү таләп иткән эш (йөк ташучы, шахтер);
- → шактый нерв-психологик киеренкелек (авиадиспетчерлар, армиядә хезмәт итү, җир өсте, җир асты һәм су транспорты йөртүче, пилот);
- → нормага салынмаган эш көне яки төнлә эшләү;
- → тискәре микроклимат (түбән яки югары температура);
- → токсик матдәләр белән бәйле эш (химия җитештерүендә эшләү).

ШКОЛЬНЫЕ БУДНИ

Менеджеры, дизайнеры, музыканты, работники науки, бухгалтеры, юристы, логисты, инженеры - да мало ли интересных профессий существует! Надо только выбрать!

Главное, что только хорошо компенсированный сахарный диабет сможет обеспечить нормальную учебу и дальнейшую работу.

УКУ ҺӘМ ДӘРЕСЛӘР ВАКЫТЫНА КИҢӘШЛӘР

Авыруларга фармацевтик һәм медицина институтларында һәм колледжларында, педагогика, авыл хуҗалыгы, икътисад, юридик институтларда, күп кенә техник югары уку йортларында укуны, китапханәләрдә, архивларда, мәктәпләрдә, сәүдә һәм башка шундый һөнәрләрне сайларга тәкъдим ителә.

Менеджер, дизайнер, музыкант, фән хезмәткәрләре, бухгалтер, юрист, логист, инженер һәм башка кызыклы һөнәрләр дә бар бит! Сайларга гына кирәк!

ДЛЯ ЗАМЕТОК

ИСКӘРМӘ ӨЧЕН

ПЕРЕВОД:
Зулейха Камалова

ДИЗАЙН, ВЕРСТКА, ИЛЛЮСТРАЦИИ:
Аделина Шайдуллина

Отпечатано в типографии ООО “Верди”
Тираж 500 экземпляров

БИК
ISBN

2020